Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Гаделша авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2026 елның 16 феврале №6/3

Татарстан Республикасы Чистай
муниципаль районы Гаделша
авыл җирлеге Советының «Физик
затлар мөлкәтенә салым турында»
29.09.2015 елның 2/1 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Гаделша авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 29.09.2015 ел, № 2/1 карарына, 2 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:
«5) карата 2 процент:
- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектлары, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш;».

2. Әлеге карарның 2 пунктындагы 5 пунктчасында каралган үзгәрешләр 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла дип билгеләргә.

3.Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга) һәм Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Гаделша авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Сабирҗанов